**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе төзү турында» 2018 елның 3 маендагы ПУ-346 номерлы Указы белән расланган Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан Ю.Л. Лихачевны чыгарырга;

б) Комиссия составына Гаязов Рөстәм Камил улын – Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе коррупциягә каршы тикшерүләр бүлеге мөдирен кертергә.

в) Комиссия әгъзалары вазыйфалары атамаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

А.Р. Арслановның – «Татарстан Республикасының күпфатирлы йортлар идарәчеләре оешмалары берлеге» ассоциациясенең үзкөйләнешле оешмасы генераль директорының хокук мәсьәләләре буенча урынбасары»;

Р.М. Каюмованың – «Татарстан Республикасының күпфатирлы йортлар идарәчеләре оешмалары берлеге» ассоциациясенең үзкөйләнешле оешмасы баш бухгалтеры»;

Н.Ф. Фатыйховның – «Татарстан Республикасының күпфатирлы йортлар идарәчеләре оешмалары берлеге» ассоциациясенең үзкөйләнешле оешмасы генераль директоры».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2019 ел, 24 гыйнвар
№ ПУ-21